**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 22 «22» декабрь 2025 ел

«Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 30.12.2022 № 59 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставы белән,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 30.12.2022 № 59 (26.07.2023 № 36, 14.06.2024 № 26, 15.07.2025 № 25 карарлар редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә, 1 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«- физик затның Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булуы яисә вафат булуы турында игълан ителүе (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очрактан тыш):

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар,

җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлар өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артыграк күләмдә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта да, бурыч өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артмаган күләмдә бурыч өлешендә мондый физик зат вафат булганнан соң өч ел узгач һәм салым органында мондый мөлкәтне мирас итеп алу факты турында мәгълүмат булмаганда.».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, «Маяк» район газетасында мәгълүмати хәбәр бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов